**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

ГЛАВА
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Пер.Совет ур., 44а
Әлкәй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«02» ноябрь 2020 ел №22

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципҭары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Әлкәй авылы Советская ур., 1нче йорттан 98 нче йортка, Школьная ур., 1 нче йорттан 42 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2020 елның 12 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Әлкәй авылы Нагорная ур., 1нче йорттан 26 нчы йортка, Нагорный тыкрыгы 19 нчы йорттан 28 нче йортка, Профсоюзная ур., 1 нче йорттан 18 нче йортка, Яңа ур., 1 нче йорттан 3а нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2020 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеген Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрүче - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты - 2020 елның 12 ноябре 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты - 2020 елның 13 ноябре 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны - Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт, Әлкәй авылы Мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2020 елның 03 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- сайлау хокукына ия булган, Әлкәй торак тункты халкы исемлеген төзергә ;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әлкәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Әлкәй авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декасы», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);

- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);

- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны вак таш түшәү җайланмасы, вак таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, Әлкәй авылы Совет урамында шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Әлкәй авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне төзекләндерү (чәчәк үсентеләре сатып алу);

- халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру (Әлкәй авылында эчә торган суның биохимик һәм бактериологик анализын үткәрү);

- күмү урыннарын карап тоту (зиратларны дератизацияләү, зират коймаларын буяу өчен лаклы материаллар сатып алу);

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык С.З.Зиннурова